**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.04.2022 №432

Территорияне планлаштыру
буенча документлар эшләү
турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары нигезендә «Проект МНК» ҖЧҖ тәкъдимен караганнан соң һәм территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә урнашкан «Карбон-Ойл» оешмасының «1557нче номерлы Мальцево нефть ятмасы скважинасы кустын төзекләндерү» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын үз акчалары исәбеннән әзерләү турындагы «МНК проекты» җәмгыятенең тәкъдимен кабул итәргә.
2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә физик һәм юридик затларның территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү тәртибе, әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен карарга һәм кабул итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин